# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘБДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**дуртенче чакырышның уникенче утырышы**

**2022 ел 10 март ае** **№ 63** **Әбде авылы**

**Теләче муниципаль районы авыл җирлеге Советының 2008 елның 15 декабрь аеның 49 номерлы «Территориаль планлаштыру документлары проектларын килештерү һәм мондый проектлар буенча бәяләмәләр әзерләү өчен Алан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан алынган мәсьәләләрне карау тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 24 мартындагы 178 номерлы карарына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 15 гыйнварындагы 16 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы авыл җирлеге Советының 2008 елның 15 декабрь аеның 49 номерлы «Территориаль планлаштыру документлары проектларын килештерү һәм мондый проектлар буенча бәяләмәләр әзерләү өчен Алан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан алынган мәсьәләләрне карау тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулда "Россия Федерациясе субъектларының территориаль планлаштыру схемалары проектлары" сүзләрен "Россия Федерациясе субъектларының ике һәм аннан да күбрәк территориаль планлаштыру схемасы проекты яисә Россия Федерациясе субъектының территориаль планлаштыру схемасы проекты"сүзләренә алмаштырырга.

2) Территориаль планлаштыру документлары проектларын килештерү һәм мондый проектлар буенча бәяләмәләр әзерләү өчен Әбде авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан алынган мәсьәләләрне карау тәртибе турындагы Нигезләмәгә:

А) 1 пунктта "Россия Федерациясе субъектларын территориаль планлаштыру схемасы проектлары" сүзләрен "Россия Федерациясе субъектларының ике һәм аннан күбрәк субъектларын территориаль

планлаштыру схемасы проекты яисә Россия Федерациясе субъектын территориаль планлаштыру схемасы проекты" сүзләренә алмаштырырга;

Б) 9 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Әбде авыл җирлеге башлыгы: Н.Р.Рахматуллин